КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 май г.Казань № 429

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 июнь, 339 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән

тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 июнь, 339 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта карарның татарча текстында «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү» сүзләреннән соң «һәм социаль партнерлыкны, гражданлык инициативаларын, иреклелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү» сүзләрен өстәргә;

4 нче пунктның сигезенче абзацында «белем бирү эшчәнлеге һәм семинарлар» сүзләреннән соң «, фестивальләр, «түгәрәк өстәлләр», коммерциячел булмаган оешмаларның социаль партнерлыкны ныгыту буенча форумнарын» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин